КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 2 ноябрь г.Казань № б-2209

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы, «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экологик иминлеге стратегиясе турында» 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә Балачак унъеллыгын игълан итү турында» 2017 елның 29 маендагы 240 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә тәрбия бирүне үстерү стратегиясе турында 2015 елның 29 маендагы б-996 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ихтыярилыкны (волонтерлыкны) үстерү концепциясен раслау турында 2018 елның 27 декабрендәге б-2950 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы халкының экологик белеме дәрәҗәсен күтәрү һәм экологик культурасын формалаштыру, экологик аң-белем бирүне һәм экологик волонтерлыкны үстерү, әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт пропагандалау максатларында:

1. 2021 елның 14 – 18 ноябрендә Татарстан Республикасы территориясендә Бөтенроссия экологик диктантын (алга таба – Экодиктант) үткәрергә.

2. Экодиктант үткәрү буенча Татарстан Республикасының төбәк оештыру комитетын (алга таба – Оештыру комитеты) төзергә.

3. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

Бөтенроссия экологик диктантын үткәрү буенча Татарстан Республикасының оештыру комитеты турындагы нигезләмәне;

Бөтенроссия экологик диктантын үткәрү буенча Татарстан Республикасының оештыру комитеты составын.

4. Экодиктантны үткәрү буенча оештыру комитетына:

Татарстан Республикасында Экодиктантны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара координацияләүне тәэмин итәргә;

Экодиктантны үткәрү буенча федераль оештыру комитеты белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга;

Экодиктантка мәгълүмат бирү характерында ярдәм күрсәтүне оештырырга;

белем, кайсы социаль төркемгә карау, дин һәм гражданлык дәрәҗәсен чикләмичә, Татарстан Республикасы халкына Экодиктант үткәрү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

офлайн форматта Экодиктант үткәрү өчен мәйданчыклар (алга таба – мәйданчыклар) исемлеген билгеләргә.

5. Экодиктант үткәрүгә әзерләнү кысаларында:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Экодиктант үткәрү турында мәгариф оешмаларына мәгълүмат бирүне;

Экодиктантта мәгариф оешмаларында белем алучыларның һәм педагогларының катнашуын;

СП 3.1/2.4.3598-20 нче «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында мәгариф оешмаларының һәм балалар һәм яшьләр өчен социаль инфраструктураның башка объектлары корылышына, эчтәлегенә һәм эшен оешты-руга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән санитария-эпидемиология кагыйдәләрен исәпкә алып, офлайн форматта мәйданчыклар эшен;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республика-сының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Экодиктант үткәрү турында үзәк аппаратлар һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар хезмәткәрләренә мәгълүмат бирүне;

үзәк аппарат һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар базасында мәйдан-чыклар эшен һәм хезмәткәрләрнең Экодиктантта катнашуын;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына Экодиктантта катнашу өчен предприятиеләр һәм зур сәүдә челтәрләрен, шулай ук Экодиктатны үткәрүдә ярдәм күрсәтү өчен партнерлар җәлеп итүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республи-касы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы һәм Татарстан Республика-сының «Чиста булачак» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы белән берлектә, офлайн мәйданчыклар эшен тәэмин итү өчен Экодиктантны оештыруга волонтерлар-экологлар җәлеп итүне тәэмин итәргә;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Экодиктантны массакүләм мәгълүмат чараларының төбәк челтәрендә яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлегенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 ноябрь, б-2209 нчы
боерыгы белән расланды

Бөтенроссия экологик диктантын үткәрү буенча
Татарстан Республикасының оештыру комитеты турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә Бөтенроссия экологик диктантын (алга таба – Экодиктант) үткәрү буенча Татарстан Республикасының оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Оештыру комитеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелә. Оештыру комитетын Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары җитәкли.

## II. Оештыру комитетының максаты һәм бурычлары

2.1. Оештыру комитеты эшчәнлегенең максаты – Татарстан Республикасы территориясендә Экодиктантны әзерләүне, үткәрүне һәм аңа йомгаклар ясауны оештыру.

2.2. Оештыру комитетының бурычлары:

Татарстан Республикасы халкының һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларының игътибарын экологик белемне арттыру мәсьәләләренә (шул исәптән Экодиктантта катнашу юлы белән) җәлеп итү;

Татарстан Республикасы халкы өчен онлайн һәм офлайн форматларда Экодиктант язу, экология өлкәсендә үз белемнәренең дәрәҗәсе турында объектив мәгълүмат алу һәм үзенең экологик белеме дәрәҗәсен арттыру, шулай ук экология тематикасы буенча белем бирү курсын үтү мөмкинлеген тәэмин итү;

эковолонтерлык хәрәкәтен үстерү һәм Татарстан Республикасы территориясендә офлайн мәйданчыклар эшен тәэмин итү өчен волонтерлар җәлеп итү;

Экодиктант үткәрү буенча федераль оештыру комитеты (алга таба – Федераль оештыру комитеты) белән координацияләп, Татарстан Республикасы территориясендә Экодиктантны оештыру максатларында ресурслар һәм бюджеттан тыш финанслар җәлеп итү.

## III. Оештыру комитетының хокуклары һәм вәкаләтләре

3.1. Оештыру комитеты:

Татарстан Республикасында Экодиктант үткәрү буенча гомуми ведомствоара координацияләүне гамәлгә ашыра;

Федераль оештыру комитеты белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

Экодиктантка мәгълүмат бирү характерында ярдәм күрсәтүне оештыра һәм аны яктырту өчен төбәк массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итә;

онлайн режимда заявка тутыру юлы белән яки республикада Экодиктант үткәрелә торган теләсә кайсы офлайн мәйданчыкка мөрәҗәгать итеп, гомуми белем бирү оешмаларында, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, һөнәри белем бирү оешмаларында, югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучыларның, 12 яшьтән зуррак Татарстан Республикасы халкының Экокодиктантта катнашуын тәэмин итә.

3.2. Оештыру комитеты үз адресына кергән Экодиктант үткәрүгә заявкаларны карап тикшерә һәм, СП 3.1/2.4.3598-20 нче «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында мәгариф оешмалары һәм балалар һәм яшьләр өчен социаль инфраструктураның башка объектлары корылышына, эчтәлегенә һәм аларның эшен оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» санитария-эпидемиология кагыйдәләрен исәпкә алып, офлайн форматта Экодиктант үткәрелә торган төбәк мәйданчыкларын раслый.

3.3. Оештыру комитеты https://экодиктант.рус/ интернет-порталында, сайтта күрсәтелгән теркәү срокларын һәм тәртибен үтәп, Экодиктант үткәрү мәйданчыкларын теркәү барышын тикшерүдә тота.

3.4. Оештыру комитеты Экодиктант үткәрү мәйданчыкларында өстәмә мәдәни программа оештыруда булышлык күрсәтә, ул курсларны, дәресләрне, мастер-классларны, шулай ук Экодиктант кысаларында оештырыла торган Бөтенроссия экология рәсемнәре конкурсының төбәк этабында җиңүчеләрнең эшләре күргәзмәләрен һәм башка чараларны үз эченә алырга мөмкин.

3.5. Оештыру комитеты халык арасында калдыкларны аерым җыюны популярлаштыру максатларында сәнәгать предприятиеләренә, калдыкларны эшкәртү белән шөгыльләнүче предприятиеләргә экскурсияләр оештырырга хокуклы (яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, уңай эпидемиологик вәзгыять шартларында).

3.6. Оештыру комитеты Татарстан Республикасы халкы арасында Экодиктант турында мәгълүмат тарату, Экодиктант үткәрү мәйданчыкларында мәдәни программа оештыру, шулай ук мәйданчыклар эшен оештыру өчен волонтерлар җәлеп итү максатларында төбәк фәнни, мәгариф, иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

3.7. Оештыру комитеты республиканың зур эш бирүчеләре булып торган коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең офлайн форматта Экодиктант үтү өчен мәйданчыклар оештыру максаты белән әлеге оешмалар белән үзара хезмәттәшлек алып бара.

3.8. Оештыру комитеты, шул исәптән Экодиктант үткәрүгә бюджеттан тыш финанслар җәлеп итү һәм аңа башка формаларда ярдәм күрсәтү максатларында партнерлар җәлеп итәргә хокуклы.

3.9. Оештыру комитеты Экодиктантта катнашучылар, волонтерлар, оештыруда катнашучылар, партнерлар өчен призлар һәм символик бүләкләр булдырырга хокуклы.

3.10. Экодиктантның мәгълүмат кампаниясен үткәрү максатларында Оештыру комитеты Федераль оештыру комитеты җибәргән полиграфия материалларын,

сувенир продукция һәм түбәндәге дизайн элементларының башка макетларын файдалана:

Экодиктант логотибы;

сайт өчен баннер;

бланклар (катнашучы сертификаты, җиңүче сертификаты, иң яхшы оештыручы дипломы, рәхмәт хаты);

социаль челтәрләрдә битләрне матур итеп эшләү өчен элементлар;

плакат һәм листовка;

пресс-волл һәм ролл-ап стенды;

журналлар һәм тышкы реклама щитлары өчен реклама модульләре;

җиңүчеләргә тантаналы тапшыру өчен кыйммәтле бүләкләр һәм сертификатлар.

3.11. Оештыру комитеты Татарстан Республикасы территориясендә Экодиктантның мәгълүмати кампаниясен оештыра, Федераль оештыру комитеты әзерләгән пресс-релизлар һәм башка мәгълүмат бирү характерындагы материалларны кулланып, республика массакүләм мәгълүмат чараларында Экодиктант турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра, шулай ук республика территориясендә Экодиктантның социаль рекламасын урнаштыруны оештыра.

3.12. Оештыру комитеты Экодиктантның мәгълүмат бирү характерындагы продукциясен (плакатлар, листовкалар) әзерләүне һәм Экодиктант үткәрелә торган мәйданчыкларда һәм Татарстан Республикасы территориясендә халык еш була торган урыннарда таратуны тәэмин итәргә, шулай ук катнашучылар һәм Экодиктантта катнашкан волонтерлар өчен бүләкләр сатып алуны һәм (яки) аларны түләүсез бирүне оештырырга мөмкин.

3.13. Оештыру комитеты, түбәндәге хэштэгларны кулланып, Оештыру комитетына керүче оешмаларның, шулай ук башка партнер оешмаларының сайтларында, социаль челтәрләрендәге рәсми төркемнәрендә һәм рәсми битләрендә Экодиктант турында мәгълүмат таратуны (Экодиктант сайтына күчү гиперсылтамасы белән Экодиктант баннерын урнаштыруны кертеп) тәэмин итә: #Экодиктант, #ФДЭБЦ, #ДрузьяЗемли, #АнгелДетствоХранитель, #АНОРавноправие, #экокультура, #экообразование, #экопросвещение, #эковолонтерство.

3.14. Экодиктант үткәрү йомгаклары буенча Оештыру комитеты республикада Экодиктант үткәрү турында кыскача мәгълүмати (фото- һәм видеоматериаллар, массакүләм мәгълүмат чараларында басмаларга сылтамалар бирелгән һ.б.) хисап төзи һәм аны Федераль оештыру комитетына җибәрә. Хисапның стандарт формасы Федераль оештыру комитеты тарафыннан бирелә.

## IV. Оештыру комитеты составы һәм аның эш тәртибе

4.1. Оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм Оештыру комитеты әгъзаларыннан тора.

4.2. Оештыру комитеты эше белән Оештыру комитеты рәисе җитәкчелек итә, ә ул вакытлыча булмаган чорда аның вазыйфаларын Оештыру комитеты рәисе урынбасары башкара. Оештыру комитеты рәисе урынбасары вакытлыча булмаган очракта, Оештыру комитеты эше белән Оештыру комитеты рәисенең кушуы буенча

Оештыру комитеты әгъзаларыннан берсе җитәкчелек итә.

4.3. Оештыру комитеты составына мәгариф, экология һәм табигать ресурслары, яшьләр сәясәте, урман хуҗалыгы, биологик ресурслар һ.б. өлкәләрдә идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының җитәкчеләре яки җитәкче урынбасарлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының матбугат хезмәтләре җитәкчеләре, фәнни, мәгариф, иҗтимагый, коммерциягә карамаган һәм житештерү оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре керергә мөмкин.

Оештыру комитетының җаваплы секретаре — балаларга өстәмә белем бирүнең табигый-фәнни юнәлешен үстерү буенча төбәк ресурс үзәге вәкиле.

4.4. Оештыру комитеты утырышлары, кирәк булуга карап, Оештыру комитеты рәисе яки аны алмаштыручы зат тарафыннан билгеләгән срокта үткәрелә.

4.5. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда Оештыру комитеты әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы була.

Оештыру комитеты карарлары утырышта катнашучы Оештыру комитеты әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Оештыру комитеты утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.6. Оештыру комитеты утырышы йомгаклары буенча Оештыру комитеты секретаре тарафыннан Оештыру комитеты утырышыннан соң биш календарь көн эчендә утырышның беркетмәсе рәсмиләштерелә, аңа Оештыру комитеты утырышында рәислек итүченең, Оештыру комитеты секретаренең имзасы куела.

4.7. Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенең күчермәсе (беркетмәсеннән өземтә) имза куелган көннән өч календарь көн эчендә Оештыру комитеты секретаре тарафыннан Оештыру комитеты әгъзаларына һәм башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

## V. Экодиктант үткәрүнең норматив-хокукый нигезе

Экодиктант үткәрүнең норматив-хокукый нигезе:

Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экологик иминлеге стратегиясе турында» 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә Балачак унъеллыгын игълан итү турында» 2017 елның 29 маендагы 240 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы;

2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экологик үсеше өлкәсендә дәүләт сәясәте нигезләре (Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2012 елның 30 апрелендә расланган);

«Экология» илкүләм проекты паспорты;

«Мәгариф» илкүләм проекты паспорты (Россия Федерациясе Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар советы президиумының 2018 елның 24 декабрендәге 16 номерлы беркетмәсе белән расланган);

Россия Федерациясенең экологик доктринасы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 31 августындагы б-1225 номерлы боерыгы белән хупланган);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экологик үсеше өлкәсендә дәүләт сәясәте нигезләрен гамәлгә ашыру гамәлләре планын раслау турында 2012 елның 18 декабрендәге б-2423 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә тәрбия бирүне үстерү стратегиясе турында 2015 елның 29 маендагы б-996 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ихтыярилык (волонтерлык) үсеше концепциясен раслау турында 2018 елның 27 декабрендәге б-2950 номерлы боерыгы;

Федерация Советының Аграр һәм азык-төлек сәясәте һәм табигатьтән файдалану комитеты белән килештерелгән, өстәмә белем бирүче «Федераль балалар экологик-биологик үзәге» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «Равноправие» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, балаларга ярдәм күрсәтү буенча «Ангел-ДетствоХранитель» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәте тарафыннан расланган, ел саен үткәрелә торган Бөтенроссия экологик диктанты турында нигезләмә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 ноябрь, б-2209 нчы
боерыгы белән расланды

Бөтенроссия экологик диктантын үткәрү буенча
Татарстан Республикасының оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Исламова Гөлнара Илдар кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры, оештыру комитетының җаваплы секретаре |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вәлиуллин Дамир Фәргать улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының мәгълүмат системалары һәм экологик аң-белем бирү идарәсе башлыгы |
| Галиева Диләрә Нургаян кызы | Казан шәһәренең «Шәһәр балалар экологик-биологик үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Галиев Тимур Рәдиф улы | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының урманнарны яңадан торгызу һәм урманнар утырту бүлеге башлыгы |
| Иванова Татьяна Александровна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү һәм укучыларының йомгаклау аттестациясе бүлеге башлыгы |
| Кондратьева Алла Андреевна | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтшин Рөстәм Рәҗәп улы | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының урманнарны яңадан торгызу һәм урманнар утырту бүлеге төп консультанты |
| Рамазанова Эльвира Зөфәр кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы баш белгече |
| Сатыйкова Диләрә Дәниф кызы | Татарстан Республикасының «Чиста булачак» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Селивановская Светлана Юрьевна | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Экология һәм табигатьтән файдалану институты директоры (килешү буенча) |
| Тарнавский Егор Александрович | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары |
| Фёдоров Андрей Александрович | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының һөнәри белем бирү идарәсе башлыгы |
| Һадиев Таһир Галимҗан улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Шәрәфетдинов Рамил Гомәр улы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары. |